1 нче вариант

I бүлек

| |
|---|
| Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз. |

I I бүлек

| |
|---|
| 2-10 биремнәрнең җаваплары буларак сүз, сүзтезмә һәм цифр күрсәтелә. |

Әни

1)Без әни белән урманга корыган ботаклар җыярга килдек. 2)Басу капкасыннан чыккач, кызыл яр кырыенда авыру кешедәй саламга төренеп утырган иске өебезне җылыту өчен, без көн саен шулай җилкә белән утын ташыйбыз. 3)Кышын да шулай, көзен дә.

4)Әнинең кулында – озын ыргак. 5)Ул аны корыган ботакка эләктерә, һәм без аңа икәүләп асылынабыз. 6)Ботак шартлап сынгач, башка төшмәсен дип, читкә тайпылабыз.

7)Шулай маташа торгач, көн дә кичекте. 8)Урманга кичке караңгы сирпелә башлады, ә безнең кайтасы җир ярыйсы ук ерак (урманнан авылны ике чакрым дип йөриләр).

9)Мин үзем күтәрәсе бәйләмне киндерә белән бәйләдем дә әнигә булыштым. 10)Ул үзенә иң авыр ботакларны җыйган. 11)Шуның өстенә тагын миннән калган чыбык-чабыкны да үз бәйләменә сыйдырмакчы булып азаплана.

12) – Җитәр инде, әни, бик авыр була, - дигәч, күтәрелеп карады. 13)Шул сүзне әйткәнгә күңеле булгандыр, күрәсең, елмаерга итте. 14)Тик, әллә бервакытта да көлеп гадәтләнмәгәнгә, әллә елыйсы килгәнгә, аның чырае яктырмады, әллә ничек кызганыч булып җыерылды гына.

15) – Нишлим соң, улым? 16)Инде бер килгәч, күбрәк кайтсын дим. 17)Көннең-көн саен утын ташып син дә бик йөдәдең, әллә берәр көн килми калырбызмы диюем иде, - диде.

18)Аның бәйләменнән бер-ике ботакны үземә алырга сузылгач, ул аларны бирмәде.

19) – Инде мин чирлисен чирләгән, улым, мине кайгыртма. 20)Син дөнья көтәсе кеше, гарип булып калма... сеңелләрең дә синең өстә... – 21)Әни сүзен әйтеп бетермәстән кинәт туктады, аркамнан сыйпап: – Синең буыннарың ныгымаган әле, шуңар гына әйтәм, - дип төзәтеп куйды.

(Гомәр Бәширов)

**2.** Татар сөйләменең үзенчәлеге булган ирен гармониясенә буйсынган сүз кулланылган җөмләне күрсәтегез.
1. Алар мәңгегә синең белән.
2. Беренче укытучысын хөрмәт белән искә алмаган кешене минем очратканым юк.
3. Яшьлектә алган сабаклар онытылмый.
4. Сәер хәл бит!

**3.** Сөйләмнең сәнгатьлелеген арттыру максатыннан фразеологик әйтелмә кулланылган җөмләне күрсәтегез.
1) Аның бәйләменнән бер-ике ботакны үземә алырга сузылгач, ул аларны бирмәде.
2) – Инде мин чирлисен чирләгән, улым, мине кайгыртма.
3) Син дөнья көтәсе кеше, гарип булып калма... сеңелләрең дә синең өстә...
4) Әни сүзен әйтеп бетермәстән кинәт туктады, аркамнан сыйпап: – Синең буыннарың ныгымаган әле, шуңар гына әйтәм, - дип төзәтеп куйды.

**4.** 12-15 нче җөмләләрдән иялек килешендәге зат алмашлыгын күчереп языгыз.
**5.** 4-8 нче җөмләләрдән аныклагыч булган җөмләнең санын языгыз.
**6**. 12-14 нче җөмләләр арасында кереш сүз булган җөмләнең номерын языгыз.
**7**. 7 нче җөмләдәге грамматик нигез(ләр)нең санын языгыз.
**8.** 2 нче җөмләдә тартым белән төрләнгән ничә исем бар?
**9.** 12-16 нчы җөмләләрдән кушма сүзне табып языгыз.
**10.** 17-19 нчы җөмләләрдән иярчен кушма җөмләнең санын күрсәтегез.

III бүлек

| |
|---|
| 2 нче бүлектә укылган текстан файдаланып, 11.1 һәм 11.2 нче биремнәрнең бары тик берсен генә сайлап алып, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез. |

**11.1** “Инде мин чирлисен чирләгән, улым, мине кайгыртма. Син дөнья көтәсе кеше, гарип булып калма... сеңелләрең дә синең өстә... – Әни сүзен әйтеп бетермәстән кинәт туктады, аркамнан сыйпап: – Синең буыннарың ныгымаган әле, шуңар гына әйтәм, - дип төзәтеп куйды” юлларында әйтелгән фикерне сез ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган текстан 2 мисал китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки текстан цитата китерегез.
Сочинениенең күләме 50 сүздән дә ким булмаска тиеш.
Сочинениене чиста һәм таныклык итеп языгыз
**11.2** Әни – җирдә иң зур кеше, - диелә татар җырында. Бу сүзләрнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? Шул турыда сочинение языгыз.Фикерегезне раслау өчен, укылган текстан 1 мисал, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән 1 мисал китерегез.